# ЎЛГЯННЯРНЕ ИСКЯ АЛЫУ ТУРЫНДА

Алла сюзе айтя: ўлгяч, ӓдямнен тяне череб тупрак була, ӓммя жаны ич кайчан бетмей, ул бу дӧньядян теге дӧньягя кючеб кня китя, аннары мянге тора.

**Алла Улы Иисус Христос** бер масял арткылы ўлгянняргя нярся буласыны кешеляргя айтеб калдырган: « Бер кеше бай икян, ул порфирдан, виссоннан теккян асыл кейемняр гня кейенгян, кӧн сайын бик шяб сыйлар жасаб кна ўткяргян. Тагы Лазарь атлы бер жарлы бар икян: ул шул байнын кабкасы тӧбӧндя кутырлы тянне кӧйӧ жаткан; Байнын ӧстяленнян тӧшкян уалчыклар белян гня булса да туйынасы килгян; анын кутырларын этляр килеб жалаганнар. Жарлы ўлгян, ўлгяч, пяриштяляр аны Авраамъ кочагына иткянняр; бай да ўлгян, аны кюмгянняр. Ул тамукта азабланган чагында, кюзлярен кютяреб караган, карагач, жырактын Авраамны, анын кочагында Лазарне кюреб, кычкырыб айткян: эй Авраамъ ӓтей! минга изгелек кылсана, Лазарне жибярсяня, ул бармагынын очон сыуга чылатыб, телемне салкыннандырсынчы, мин бу жалкында азабланам шул, дигян. Авраамь айткян: улым! син тормошонда рахатляндең, ӓммя Лазарь азабланды, шуны исеня тӧшӧр; казер инде ул мында сӧйӧнӧб тора, ӓммя син азабланасың; Аннан былай тагы да безнен белян сезнен арада бик зур тӧбсӧз урын куйылган, шунныктан мыннан сезнен катка кючясе килеўчеляр кючя алмыйлар, сезнен каттан безгя дя кючмейляр, дигян. Аннары бай айткян: айса синга ўтенямен, ӓтей, аны минем атам ӧйӧня жибярсяня; Минем биш агай-энем бар, мындагы халне ул аларга айтеб кюрсятсен, алар да бу азаб урнына килмясенняр эйе, дигян. Авраамъ ангар айткян: аларнын Моисейе бар, пагамбярляре бар, аларны тыңнасыннар, дигян. Ул айткян: эй Авраамъ ӓтей! жук, ӓгяр беряў-беряў аларга ўлгян жиреннян терелеб кайтса, алар тяўбя итярляр, дигян. Шунда Авраамъ ангар айткян: Моисейне дя, бютян пагамбярлярне дя тыңнамагач, беряў-беряў ўлгян жиреннян терелся дя ышанмаслар, дигян» (Лк. 16, 19-31).

Шул Христоснын сюзляреннян без белябез ничек жазыклы жаннарнын азаблары бик жаман икянен. Алар анда шайтаннар белян бергя торалар, ней эшляргя белмейче, жалан кӧйӧнӧб торалар. Изге, гадел жаннар жомакта Алланы кюреб торганнарына сӧйӧнӧшяляр, Алла Анасын, Алланын изге пяриштялярен, бар ӓулеялярне кюреб торганнарына кыуаналар.

Ўлгянняр ӧчӧн иманнар, Псалтирь укыйлар. Бигеряк священникляргя инялдерергя киряк. Панихида телягендя священник ўлгяннярнен исемнярен айтеб, Ходайга иняля: *«Эй Ходай, ўлгян мяндяляреңнен жаннарын жакты, иркен, тыныч урынга, ич-бер ауыртыу, кӧйӧк, кайгырыу жук жиргя урыннаштырыб рахятлектя тот. Ўзең ӓдямне сӧйӧўче изгелекле Аллага кюря, аларнын сюз белян, жя эш белян, жя уй белян кылган жазыкларын кичер»*, диб. Ўлгянняр ӧчӧн тагы бигряк тя чиркяўдя Литургия келяўендя, кансыз Корман китергян чакта инялергя киряк. Христианнар былай искя алалар: чумылган кешелярнен исемнярен жазыб, чиркяўгя биряляр. Священник жазыудан караб, ўлгяннярнен исемнярен айтеб, ӓр-берсе ӧчӧн просфорадан беряр кисяк кисеб ала да, дискос ӧстӧня куя. Бу кисяклярне священник суңыннан ўзе Ӧлӧш алгач, Христоснын сауыттагы Каны ӧстӧня: «*Эй Ходай изгеляреңнен телякляре хакына, мында айтелгян кешелярнен жазыкларын арыу Каның белян жыуыб бетер»*, диб сала.

Бер кеше Иисус Христостан сораган: *«Жомакка, мянге тормошка урыннашыр ӧчӧн, мин ней кылыйым? дигян. Ходай айткян: Алла Ходайыңны бар кюңелең белян, бар жаның белян, бар кӧчӧң белян, бар уйын белян сӧй, жакыныңны да ўзеңне сӧйгян кюк сӧй»*, диб.

*Ӧй-хужалыгында кулланмаска!*